# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлеге Әхмәтовка торак пунктында 2024 елда гражданнардан үзара салым кертү турында

**20 ноябрь 2023ел** **№ 3**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ЗРТ атарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең Әхмәтовка торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1.«2024 елда Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең Әхмәтовка торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге уку формасында укучы студентлар, Россия армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

-Куян торак пунктында парк төзү өчен материаллар сатып алу (профнастил, такталар, торбалар; килешү буенча эш өчен түләү).

3. Бикбау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән әлеге карарны игълан итәргә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында http://menzelinsk/tatarstan.ru, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Бикбау авыл җирлеге башлыгы: Л.Н. Мәрдамшина